СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26.01.2016 ел** **№ 2**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2016 елда Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлардан 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу; Яңа Кишет авылы | 15 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу).<br>Яңа Кишет авыл җирлеге территориясенә кергән барлык авылларда | 126 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - Яңа Кишет авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;<br>-Чишмәләр төзекләндерү | 8 000<br><br>12 000 |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Кшкар авылына скважиналар өчен насос алу | 7 000 |
| | | Барлыгы: | 168 000 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Яңа Кишет авылы, Дуслык ур., 100а.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов